РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКАРМАИНСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Центральная, 4,с.Большие Кармалы,
422830,
тел. (8-843-77)35-2-38, факс: (8-843-77) 35-2-38
ОКПО 93065191 , ОГРН 1061672018022
ИНН/КПП 1622004612/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ОЛЫ КАРАМАЛЫ**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Үзәк урамы, 4, Олы Карамал авылы,
422830,
тел(8-843-77)35-2-38. , факс: (8-843-77) 35-2-38
ОКПО 93065191, ОГРН 1061672018022
ИНН/КПП 1622004612/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**21.06.2023 ел** **№ 6**

**Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында Карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенең» 2023 елнын 26 апрелендэге №409 хаты нигезендэ, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Олы Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
Мәчет территориясе;
Мәдәният йорты территориясе;
Почта элемтәсе бүлекчәсе территориясе;
Сәүдә объектлары территориясе;
Балалар мәйданчыклары территориясе;
Һәйкәл һәм обелиск территориясе.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Байдамшин Эдуард Илгизәр улын хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүче вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Карамалы авылы, Үзәк ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, 16 , Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан коненнэн үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе ____________________ Э.И.Байдамшин